# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Югары Аты авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**“20” ноябрь 2024 ел** **№ 9**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2024 елның 20 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

« Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Югары Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1 нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү ,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгы өчен материаллар сатып алу һәм койма кору; ремонт эшләре үткәрү ; МТЗ 82.1 тракторы өчен асылмалы җайланмалар сатып алуны финанслау (роторлы кар чистарткыч )) ?”

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 159 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 91 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 91 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар- Аты авыл җирлегендә Югары Аты авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип таныrга.

2. « Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Югары Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы

студентлардан, 1 нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү ,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгы өчен материаллар сатып алу һәм койма кору; ремонт эшләре үткәрү ; МТЗ 82.1 тракторы өчен асылмалы җайланмалар сатып алуны финанслау (роторлы кар чистарткыч )) ?"

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" - 91 "КАРШЫ"-0

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә ТР, Арча районы, Югары Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева